*/Безнең уңышлар/*



### *Матур язуда уңышларыбыз*

Республикабызның олимпиада үзәге ел саен төрле фәннәрдән олимпиадалар үткәрә. Безнең укучылар бу чараларга әзерләнеп актив катнаша. Сентябрь аенда "**Матур язу серләре"** дип аталган конкурста, алдагы еллардагы кебек үк, безнең укучылар һәм балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр катнашты. Бу бәйге укучыларда пөхтәлек, җаваплылык, эшне ахырына кадәр җиткерү кебек сыйфатлар тәрбияли. "Матур язу серләре" 3 этаптан тора. 1 нче бурыч – өй эшенә бирелгән текстны дөрес итеп, каллиграфияне саклап күчереп язу. 2 нче эш итеп каллиграфия элементлары кертеп яңа алфавит язу һәм аны матур, чиста итеп бизәү йөкләмәсе бирелә. 3 нче очный турдагы эшләр грамматикага кагыла. Монда биремнәрне кагыйдәләрне искә төшереп эшләү бурычы куела.

Безнең укучылар олимпиада биремнәрен уңышлы үтәделәр. Чөнки бу укучылар балалар бакчасыннан ук моңа әзерләнәләр. I сыйныфтан **Гафиятуллина Руфинә**, II сыйныфтан **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур**, III сыйныфтан **Нурматова Асия**, IV сыйныфтан **Донсков Артур**, V сыйныфтан **Ахсанова Мәдинә, Закирова Ләйсән, Насыйрова Кәүсәрләр** бернечә ел рәттән бу конкурста җиңеп киләләр. III сыйныфтан Хусенов Дмитрий белән балалар бакчасыннан **Галиаскәрова Асия** призер булдылар. Республика буенча да аларның баллары югары иде. Район буенча нәтиҗәләрне чагыштырганда, безнең укучыларның баллары иң югарысы булды.

Укучыларны әзерләүдә көчләрен куйган укытучыларга, тәрбиячеләргә, әти-әниләргә рәхмәт җиткерәсем килә. Балаларга уңышлар, мондый чараларга ешрак катнашып, үзләрен үстерүләрен телим. Йөргән таш кына шомара!

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***




### *Милләтләр кроссы - 2022*

*/Безнең спорт/*

Ел саен уздырыла торган республикакүләм кросста без – югары сыйныф укучылары - теләп катнашабыз. "Милләтләр кроссы" спорт чарасы гына түгел, ә гомумроссия масштабындагы социаль әһәмиятле вакыйга да. Аның төп максаты – сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм илнең халкын, барыннан да элек яшьләрне, физик культура белән шөгыльләнүгә җәлеп итү. Шулай ук бу чара зур һәм күпмилләтле илдә яшәүчеләрне бер гомуми вакыйгага җәлеп итә. Бүгенге чорда мондый спорт чаралары бик урынлы санала. Чөнки күпчелек кешеләр бүгенге көндә бик аз хәрәкәтләнә.

***Камалов Илдус, XI сыйныф укучысы***



*/Чал тарихта эзле без!/*

### *"Үз мәктәбеңә ярдәм ит!" чарасы тарихыннан*

Барыбызга да билгеле булганча, Татарстанда 2013 нче елдан алып «Үз мәктәбеңә ярдәм ит!» дигән хәйрия акциясе уздырылып килә. Бу чараның максаты – төрле елларда белем алып киткән элеккеге укучыларны туган мәктәпләренә матди ярдәм күрсәтүгә җәлеп итү. Безнең авылда әлеге чара массакүләм рәвештә 2014 нче елда – мәктәпнең яңа бинасы ачылу уңаеннан уздырылган иде. Бу елны яңа мәктәпне котлап 200 000 сумнан артык бәягә бүләкләр тапшырылган иде. Аннан соңгы елларда, зур күләмдә булмаса да, мәктәпкә ярдәм итүчеләр булгалап торды.

Тарихка күз салсак, үз мәктәбеңә ярдәм итү безнең авылда моннан ярты гасыр элек тә гамәлдә булган икән. Менә бу ретро-фото шундый хәйрия чарасының шаһиты булып тора. Ул 1965 нче елның 1 нче сентябрендә, Түбән Майнада сигезьеллык мәктәп ачылу тантанасы вакытында төшерелгән. Бирeдә без авыл советы рәисе Хафизов Шакир абыйның яңа мәктәпнең беренче директоры Рифкать Насыйбуллинга ата-аналар мәктәпкә алып биргән телевизорны тапшыру мизгелен күрәбез. Ул заман балаларының күпчелеге телевизорны беренче тапкыр шәт мәктәптә генә күрә алгандыр.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы***


**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина



# *Мәктәп хәбәрчесе*

**№7**
**(№38)**
**сентябрь**
**2022 ел**

***Түбән Майна урта мәктәбе газите***



**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**




*/Мөхәррир минбәре/*

### *Белем бәйрәме белән!*

Бүген 1 нче сентябрь. Бүген укучылар тормышында тагын бер яңа сәхифә ачыла. Ел саен меңләгән беренче сыйныф укучысы олы тормышка юл башы булган мавыктыргыч белем дөньясына алып кергән беренче кыңгырау чыңын көтә... Менә тагын сентябрьнең аяз һәм җылы иртәсендә мәктәп тирәсе күңелле шау-шуга күмелде. Укытучылар, укучылар, әти-әниләр, килгән кунаклар мәктәп ишегалдында очраша. Алар барчасы да елмайган һәм күтәренке кәефле. Һәр укучыда яраткан укытучысына бүләк ителәсе чәчәк бәйләме. Белем, мәктәп, укытучы турындагы җырлар бер-бер артлы агыла. Шул күңелле көйләргә кушылып, укучыларның ничәмә-ничә буынын дәрескә чакырган җиз кыңгырау да ал бантиклардан бәйрәмчә "киенеп" безне каршылый. Аның бүгенге чыңлавы моңсу түгел, ә дәртле һәм эшлекле яңгырый. Гыйлемнең кеше өчен иң зур байлык икәнен онытмаска, алдагы уку елында тагын да тырышып белем эстәргә чакыра кебек кыңгырау.

Быелгы Белем бәйрәме тамашасын һәрвакыттагыча IX һәм XI нче сыйныфлар алып барды. Мәктәп директоры Насыйров Рафик бәйрәмне ачып, барлык мәктәп хезмәткәрләрен, укучыларны, авылдашларны олы бәйрәм белән котлады. Узган уку елына нәтиҗәләр дә ясады. Беренче сыйныфларны аерым котлап, укуларында тырышлык теләде. Район вәкиле Сәхабетдинов Мансур Шамил улы бәйрәм белән котлап, укучыларга тырышып укырга, киләчәктә авылыбыз, районыбыз өчен кирәкле һөнәр ияләре булырга чакырды. Ветеран укытучы Исмагилов Рафик абый үзенең "Мөгаллимнәр" шигырен укыды, укучыларга белем алуда тырышлык, иҗадилык теләде.

Башка бәйрәмнәр белән чагыштырганда, 1 нче сентябрь чарасында буыннар алмашуы бик ачык күренә. Бәйрәм түрендә XI сыйныфның 4 укучысы белән I нче сыйныфка керүче 2 укучы – **Гафиятуллина Руфинә** белән **Хафизов Илфат** урын алган. Без аларның барчасына да гыйлем үрләрен яулаганда зур уңышларга ирешүләрен телибез. Быелгы уку елында хезмәт юлларын Майна мәктәбе укучыларына белем бирүгә багышлаган өч өлкән буын мөгаллимәбез – **Гафиятуллина Зөлфия апа, Нәҗметдинова Рушания апа, Хәсәнова Ризидә апаларны лаеклы ялга озаттык.** Аларга алмашка мәктәп коллективына яшь укытучы – **Хәбибрахманова Сафия** кушылды. Ул Түбән Кама педагогика көллиятен тәмамлап, моннан 4 ел элек тәгәлләгән туган мәктәбенә эшкә кайтты. Без Сафиягә сайлаган һөнәренең уңыш китерүен, балаларны яратып, аларның мәхәббәтен яулап, озак еллар эшләвен телибез.

***Фәнүзә Гафиятуллина, "Мәктәп хәбәрчесе" мөхәррире***

*/Рәсми хәбәрләр/*

### *2022-2023 нче уку елындагы үзгәрешләр*

Россия һәм Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыклары тарафыннан быелгы уку елыннан мәктәпләр эшчәнлегенә шактый үзгәрешләр кертелде. Башлангыч һәм төп гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларының эчтәлеге яңартылды. Урта гомуми белем бирү федераль дәүләт мәгариф стандартларына үзгәрешләр кертелде. I һәм V сыйныфлар яңа программа белән укый башлыйлар.

Шулай ук, яңа уку елыннан башлап, илебездәге барлык мәктәпләрдә дә дәресләр вакытында укучыларга кесә телефонын куллану (сөйләшү, шалтырату, уйнау) тыела. (Әйтергә кирәк, безнең мәктәптә укучыларның кесә телефоны йөртүе моннан биш ел элек үк тыелган иде.) Россиянең барлык мәктәпләрендә дә һәр атнаның дүшәмбесе дәүләт гимны астында ил флагын күтәрүдән башланачак. Безнең республикада Россия һәм Татарстан гимннары яңгыраячак һәм флаглары күтәреләчәк. Һәр атнаның сишәмбесендә укучылар өчен "Разговоры о важном" дигән махсус дәрестән тыш чаралар уздырылачак. Бу чарада җәмгыятебез өчен мөһим темалар яктыртылачак.

Сыйныфтан тыш эшчәнлеккә килгәндә, быелгы уку елыннан түгәрәкләр үзгәрде. "Яшь лингвист" һәм "Оста куллар" урынына мәҗбүри кертелгән ЮИД һәм театр түгәрәкләре эшләячәк. Дәрестән тыш чаралардан, алдагы елларда гамәлгә кертелгән финанс белемлелегенә, эшмәкәрлек осталыгына өйрәтә торган курс өстәләчәк.

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

**/Мәктәп тормышы/**



## Яңа уку елына әзерлек

Мәктәпнең заман таләпләренә җавап бирерлек матди базасы булу зур әһәмияткә ия. Соңгы елларда, бюджеттан тыш керемнәр һәм экономияләнгән финанслар исәбенә, безнең мәктәпкә бик күп яңа җиһазлар алынды. Хәзерге вакытта безнең бакча төркеме, ашханә, спортзал, уку кабинетлары кирәкле әйберләр белән тулысынча диярлек тәэмин ителгән. Узып баручы цифрлаштыру елында мәктәп яңа компьютерлар, ноутбуклар, видеопроекторлар белән тиешле дәрәҗәдә җиһазландырылды. Яңа уку елына әзерлек барышында, агымдагы ремонт эшләренә кирәкле материаллардан тыш, фән кабинетлары һәм лабораторияләр өчен 500 000 сумнан артык бәягә төрле приборлар һәм укыту әсбаплары кайтара алдык. Чөнки биология, химия, физика, география кебек табигать фәннәре өчен лаборатор җиһазлар юк дәрәҗәсендә, ә булганнары физик һәм мораль яктан нык тузган иде. Шулай итеп, мәктәбебез яңа уку елын тагын да зуррак мөмкинлекләр белән башлап җибәрде. Булган байлыкның кадерен белеп укырга һәм эшләргә генә кала.

***Рафик Насыйров, мәктәп директоры***

## «Игътибар, балалар» акциясе



Республикада "Игътибар - балалар!" кисәтү акциясе старт алды. Әлеге акциянең төп максаты - балалар катнашында килеп чыккан юл фаҗигаләренең санын киметү. Акция барган чорда юл йөрү кагыйдәләрен бозучы балалар аеруча нык контрольгә алыначак. Юлны светофорның кызыл утына чыккан, велосипедта тиешсез урыннарда йөргән укучыларга махсус карточкалар тутырылып мәктәпләргә җибәреләчәк. Шулай ук тиешле тизлекне сакламаучы, җәяүлеләргә юл бирмәүче, балаларын махсус автоурындыклар белән җиһазландырмаган килеш юлга чыкканнарга да таләпләр катгый булачак.

Алда әйтеп үтелгәнчә, агымдагы елның 7 аенда республикада балалар катнашында 328 юл фаҗигасе булды. Транспорт йөртүчеләр гаебе белән дә шактый юл фаҗигаләре, балаларның гомере өзелүләре фактлары теркәлде. Сентябрьнең беренче унконлегендә "Балалар, игътибар, җәяүлеләр кичүе" акциясе бездә дә уздырылды. Мәктәпнең ЮИД отряды әгъзалары башлангыч сыйныф укучыларына җәяүлеләрнең юл йөрү кагыйдәләрен аңлаттылар. Юлга чыгып, төрле катлаулы хәлләрдә калганда үзеңне тоту кагыйдәләрен кабатладылар. Авылдашыбыз Габдуллин Гомәр абыйны туктатып, чын әңгәмә оештырдылар. Ә күп стажлы машина йөртүче Гомәр абый балаларга юлда ничек үзеңне тоту турында сөйләде. Кеше гомере бер тапкыр гына бирелә, шуңа күрә җәяүлеләр дә, руль артындагылар да юл йөрү кагыйдәләрен катгый үтәргә тиеш.

***Виктория Нукина, XI сыйныф укучысы.***



## Яңа формага күчтек

***"Кешенең бөтен нәрсәсе дә матур булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, күңеле дә, фикере дә"*** диеп әйтеп калдырган рус классик язучысы Антон Чехов. Бу сүзләр белән һәркем килешер. Сүзебез мәктәп формасына кагыла. Аңа булган таләпләрне гәзитебез битләрендә моңа кадәр дә язган идек. Шулай да формага карата дөрес карашны бернечә ел тәрбияләргә тырыштык. Быел инде, укытучылар һәм әти-әниләр белән киңәшләшеп, яңа формага күчүне оештыра алдык. Форма ул үзеңнне-үзең тәрбияләү дә дигән сүз. Бер төрле кием дисциплинаны яхшырта, бер-берсеннән аерылып торуга юл куймый. Кызларга, егетләргә карап торуы күңелле. Алар быел үзләрен җитдирәк тә тоталар кебек.

Түбән Майна мәктәбе укучысының формасы куе зәңгәр төстәге тукымадан тегелгән. Малайларның төп формасы – жилет белән чалбар, кызларныкы – сарафан. Төп форма эченнән ак иясә ачык зәңгәр төстәге күлмәк иясә блузка киелә.

Хәзерге формадан укучылар да, укытучылар да канәгать. Балалар белән төрле чараларга йөргәнгә күрә, район укытучылары тарафыннан да киемебезгә карата җылы сүзләр ишеттек.

***Рузилә Хәйруллина, башлангыч сыйныфлар укытучысы***

**/Укучылар иҗаты/**



## Ятим авылым

Минем туган авылым – Яңа Татар Әдәмсуы. Безнең авыл матур урынга урнашкан. Болыннар, әрәмәлекләр – бар да үз урынында. Халык үз тырышлыгы белән яшәп көн күрә. Авылдашлар шушында үз бәхетен тапканнар. Әти-әнием дә төп йортны саклап, авылны яратып, шунда эшлиләр. Безне дә үз хезмәтең белән яшәргә дип тәрбиялиләр. Дәү әнием минем белән һәрвакыт дәрес әзерләшә. Авылдашлар турында төрле истәлекләрен сөйли. Авылыбыз кайчандыр гөрләп торган, күп кеше булып, барысы дус-тату яшәгәннәр.

Тик бүген мин авылның бердәнбер баласы булып калдым. Мәктәпкә бару өчен берүзем юлга чыгам. Көзге караңгы иртәләр, кышкы салкыннар укырга йөрергә куркытмаса да, ялгыз кызык түгел. Минем авылым бүген ятим язмышын кичерә кебек. Авыл буйлап атлаганда, буш калган нигезләрне, йортларны карап чыгам. Буш йортларның тәрәзәләре шундый күңелсез карыйлар миңа, әйтерсен алар миңа үзләренең хәсрәтләрен сөйлиләр. Тәрәзәләрдә хуҗалар карашы саклана бугай. Аларның берсе дә елмаеп карамый, гөлләр дә үсми анда. Ташлап киткән балаларын көтәләр сыман алар.

Мондый фаҗига кабатланмасын иде дә, тик күбесе авылдан китү ягын гына карый. Ә авылда барыбер тыныч, рәхәт бит. Үзебез үскән, әтиләр төзегән нигезләрне кадерсезләмәсәк ярар иде дим. Китүчеләр дә сүземне ишетеп, кайтып бераз барласагыз иде әтиләрегез калдырган өйләрне.

***Камил Төхвәтуллин, V сыйныф укучысы***



## Авылым байлыгы – өстәлем нигъмәте

Мин авылда яшим. Шуңа күрә табигатьнең һәр үзгәреше миңа яхшы таныш. Кышның аклыкка күмгәне дә, зыкы салкыны да якын. Язын урам кошлар тавышы белән матур. Җәй инде, билгеле, каникулы белән ямьле. Ә көз, әлбәттә, байлыгы белән көчле ул. Авыл кешесе көзен бакчасында үстергән барлык төр яшелчәсен җыеп, кышкылыкка әзерли. Безнең базларда булган байлыкны кыш буена да ашап бетереп булмыйдыр. Чөнки әнием әллә никадәр салатлар ясый, кыяр-помидор тозлый. Туганнарга да күп өләшә әле. Безне дә хезмәткә өйрәтә. Әнем белән тигез итеп эшлибез. Хезмәтебез әйбәт барганда безне мактап та куя әни. Кышка тәмле ашарсыз дип эшкә күндерә. Дөрес, кышкы озын төннәрдә әнием ясаган тәмле кайнатмалар белән чәй эчү бик рәхәт була. Әтием белән бабам да, энем дә бу сыйларны бик ярата.

Кырларда да урак өсте көзнең байлыгын исбатлый. Икмәкләр җыеп алынып амбарларга күчте. Икмәк булып өстәлгә килгәнче озын юллар үткән алтын бөртекләр ничек инде тәмле булмасын. Өчпочмак, бәлеш, токмачлар өстәлләребездә һәрвакыт тулып торсын иде. Әниләр, әбиләр пешергән тәмле камыр ризыклары да, бакча уңышы да безнең үзебез үстергән байлык санала. Аларны үстерүче игенчеләргә зур тырышлыклары өчен рәхмәт әйтәсем килә. Авыл хезмәтчәннәренең уңганлыгы безнең өстәлләрдә икән.

***Ләйсән Закирова, V сыйныф укучысы***

## Көзге уңыш



Эшләмәсән җәй көне, ни ашарсың кыш көне, ди халык. Укучыларга хезмәт тәрбиясе бирү һәм җәйге ялны файдалы итү өчен, мәктәптә яшелчә бакчасы тотыла һәм чәчәкләр үстерелә. Без җәйге каникул вакытында практикага килеп, түтәлләрне йомшартабыз, чүп үләннәрен утыйбыз, су сибеп тукландырабыз. Практика җитәкчеләребез белән берлектә бакчабызны тәртиптә тотарга тырышабыз.

Быел да мәктәп бакчасында елдагыча яшелчәләр үстерелде. Бәрәңге уңышы быел аеруча шатландырырды. Орлык өчен дә, укучыларга ашау өчен дә җитәрлек булды. Кишер, суган, чөгендерләр дә алынып, саклауга куелды. Пешерүче апаларыбыз безгә кыш буе яшелчәләрдән витаминлы салатлар ясыйлар.

***Кәүсәр Насыйрова, V сыйныф укучысы***

**/Котлыйбыз!/**



Сентябрь аенда туган көнен билгеләп үтүче дусларыбыз – бакча төркеменә йөрүче ***Елисеев Аделне***, 5 нче сыйныф укучысы ***Төхвәтуллин Камилне*** котлыйбыз. Аларга саулык-сәламәтлек белән, көчле, акыллы һәм булдыклы егетләр булып үсүләрен, үсеп җиткәч тә, әти-әниләренең терәкләре булуларын теләп калабыз.

Җитәкчебез ***Насыйров Рафик Гомәр улын*** гомер бәйрәме белән ихластан котлап, ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, иҗади уңышлар теләп калабыз.